ЯКШӘМБЕ
28
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 49 (6771)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

## КОМСОМОЛ, АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРҮДӘ ИНИЦИАТОР БУЛ!

Партиябезнең турылыклы алмашы—комсомол—үзенең бөек исемен намус белән аклый. Без комсомолецларны ватан сугышы фронтларында батыр сугышчылар, куркусыз партизаннар арасында күрәбез. Фронт өчен армый-талмый кораллар әзерләүче, мул итеп ашлык һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүче тыл гвардеецлары арасында күпләп очратабыз.

Комсомолецлар күп кенә гүзәл эшләрнең инициаторы булып килделәр һәм киләләр.

Республикабызның Биектау районы комсомолецлары инициативасы белән күп кенә яшь терлекләр шефка алынды. Ул терлекләр таза һәм сәламәт булып үстеләр. Оборона гектарлары чәчүне дә башлап комсомолецлар оештырдылар. Октябрь районы комсомолецлары йөзләрчә кызыл обозлар оештырып, дәүләткә ашлык тапшыру планының үтәлешен шактый арттырдылар. Нагорный методын куллануда да комсомолецлар инициатор булдылар.

Югары игән уңышы алу өчен көрәштә комсомолның роле гаять зур. Һәрвакытта эшнең иң кирәкле участогында булу һәм анда оешканлык үрнәкләре күрсәтү—комсомолецларга хас сыйфат. Бу сыйфат икенче хәрби язны каршылаганда аеруча ныгырга тиеш. Комсомол өлкә комитетының VII нче пленумы карарлары нәкъ менә шул турыда сөйлиләр. Колхозчы комсомолецларга авыл хуҗалыгы эшләре буенча сугыш вакытында тагын да күбрәк җаваплылык йөкләнә. Михаил Иванович Калинин алдынгы колхозчы комсомолецларны кабул иткәндә болай диде:

«Сезнең өстегезгә хуҗалык өчен җаваплылык йөкләнә. Димәк, беренче чиратта ватан өчен күбрәк кирәк булган урында эшләргә кирәк. Сезгә тизрәк тәҗрибәле кешеләр булып, колхоз производствосын белүче эш хуҗалары булып эвереләргә кирәк. Агроном юк икән, аның урынында эшләргә кирәк. Һәрбер колхоз оешмасында хуҗалыкның кайсы булса да бер ягын—кырчылыкны, терлекчелекне тирәнтен өйрәнүче, игенчеләрдән, яшелчәләрдән, бәрәңгедән, житеннән югары уңыш алу юлларын эзләүче кешеләр булуга ирешергә кирәк».

Иптәш Калининның бу өйрәтүен тормышка ашыруның хәзер иң яхшы вакыты. Хәзер кышкы агротехника чараларын тулысынча үткәрү өчен көрәшнең иң кызу чагы. Бу турыда ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы да нык кисәтү ясады һәм аны оештыру юлларын күрсәтте. Шулай ук, ВЛКСМ Өлкә Комитетының VII нче пленумы авыл комсомолының алдына конкрет бурычлар куйды. Большевиклар партиясенең булдыклы ярдәмчесе—комсомол бу өлкәдә җиң сызганып эшләргә тиеш.

— Барлык комсомолецлар һәм барлык яшьләр агротехника белән җитди гәешләр шөгыльләнергә тиешләр. Пленумның күрсәтмәсе менә шул. Шушы якын көннәрдә, авылдагы комсомол оешмасының һәрбер намуслы члены 50 килограмм көл, 20 килограмм кош тизәге җыярга, колхозчыларның һәм хезмәткәрләрнең ишек алларыннан 15 йөк тирес чыгарырга һәм берәүке гектар мәйданда кар тотарга тиеш. Бу, сугыш вакытында авылдагы һәрбер комсомолецка карата фронтның таләбе. Фронт таләбе комсомолларча тәгәллек белән үтәлергә тиеш.

Һәрбер комсомол оешмасы янында чәчү орлыгы салу һәм тазарту буенча комсомолецлардан, яшь колхозчылардан һәм совхоз эшчеләреннән звенолар төзүгә дә мөһим чара дип карарга кирәк. Орлыкның язгы чәчүгә әзерлеген тикшерү буенча 10 нчы марттан 1 нче апрельгә кадәр үткәреләчәк 2 ун көнлекнең уңышлы нәтиҗәләр китерүе, аңа әзерлекне яхшы оештыруга һәм бу звеноларның эшлеклелегенә бәйләнгән булуын истән чыгармаска кирәк.

Язгы чәчүгә әзерлек буенча комсомолецлар үзләре алдына куелган бурычларны уңышлы үтәсеннәр өчен, башлангыч партоешмалар тарафыннан житәкчелекне һәм булышлыкны тәэмин итәргә кирәк.

Колхозчы комсомлецлар һәм комсомолкалар! Язгы чәчүгә әзерлек буенча үзегезгә йөкләтелгән бурычны тәгәл үтәүне тәэмин итегез, союздан тыш яшьләрне шуңа туплагыз, фронт интереслары сездән шуны таләп итә.

## *Москва, Кремль, иптәш Сталинга*

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Бөтен монгол халкы, хөкүмәт һәм партия исеменнән, безнең революцион халык армиясенең цириклары һәм командирлары исеменнән Сезне һәм Сезнең аркылы бөтен совет халкын һәм аның героик армиясен Кызыл Армиянең данлыклы 25 еллыгы белән чын күңелдән котлыйм. Советлар Союзының кораллы көчләре үзенең юбилеен безнең халыкларыбызның намусына, азатлыгына һәм бәйсезлегенә кул сузган немец фашизмына каршы бөек ватан сугышы шартларында, батыр Кызыл Армиянең, уңышлы һөҗүм сугышлары алып барып, совет җирен немец-фашист басып алучылардан чистартуы шартларында искә алып үтәләр. Сталинград, Воронеж янында гитлерчы оккупантларны тар-мар итү, Ростовның, Харьковның, Ворошиловградның, Курскиның, Ставропольнең, Краснодарның һәм күп меңнәрчә совет шәһәрләренең һәм авылларының фашист кабахәтләрдән азат ителүе куәтле Кызыл Армиянең җимергеч көчен күрсәтә. Аның бик яхшы хәрби техникасы бар, аның үз ватанына чын күңелдән бирелгән, сугыш сәнгатен бик яхшы үзләштергән тагын да гүзәлрәк сугышчылары һәм командирлары бар. Бу—явыз дошманны җиңәчәгебезгә безнең ышанычны ныгыта. Бу—фронтка ярдәм итүне көчәйтү өчен безнең көчләребезне арттыра.

Сезнең 1943 нче елның 2 нче февралендә безнең делегациябезне кабул итүегез һәм безнең Кызыл Армиягә күрсәткән кечкенә генә ярдәмебез өчен Сезнең югары бәя бирүегез—аталарча рәхмәт әйтүегез бездә әлегәчә булмаган энергия дулкыны тудырды. Сезнең белән очрашу—ул, безнең халкыбызның бөек рус халкы белән һәм гомуми дошманыбызга—гитлеризмга каршы изге көрәштә берләшкән Советлар Союзы халыклары белән иң якын туганлык дуслыгының чагылышы булды. Безнең халкыбыз хәзерге вакытта үзе өчен бөтен көче белән фронтка ярдәм итүдән дә әһәмиятлерәк булган бурыч бар дип белми. Соңгы өч ай эчендә генә дә безнең республикабызның хезмәт ияләре СССР га ярдәм фондына 8 миллион тугриктан артык акча керттеләр. Хуҗалык, культура һәм оборона төзелешендә безнең илебезгә чын күңелдән күрсәтелгән ярдәм өчен Сезгә, большевиклар партиясенә һәм Совет халкына кайнар мәхәббәт һәм рәхмәт йөзеннән, Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән Кызыл Армия өчен ватаныбызның намуслы патриотларының куллары белән әзерләнгән ике эшелон яңа бүләк җибәрелде. Шулар арасында безнең халкыбыз безгә якын һәм туган булган Кызыл Армия сугышчыларына, командирларына 12 мең пар киез итек, 12 мең пар күн итек, 3 мең пар ботинка, 10 мең шинель, 3 мең данә сырган костюм, 1 мең данә кавалерия ияре, 10.500 данә кавалерия кәешы, 36 тирмә, 625 велосипед, 15 мең баш кыр антилопасы, 500 баш кабан дуңгызы, 16 мең баштан артык көртлек, 68 тонна май, 70 тонна казлык, 65 тонна балык, 78 тонна кондитер әйберләре һәм конфетлар, 30 тонна сабын, шулай ук киез, унта, тапочка, бияләй, доха, күн пальто һәм шулар өстенә 16 меңнән артык индивидуаль посылкалар җибәрде.

Немец фашизмына каршы көрәштә гомуми эштә безнең бу бүләкләр хәлдән килгән кадәр ярдәмебез булсыннар.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы көнендә Сездән Кызыл Армиянең барлык сугышчыларына һәм командирларына Монголия хезмәт ияләренең чын күңелдән булган теләкләрен—немец юлбасарларны тәмам юк иткәнчегә кадәр рәхимсезлек белән тармар итәргә дигән теләкләрен тапшыруыгызны үтенәм.

Ерткыч фашизмга каршы бергәләшеп көрәшү өчен берләшкән, азатлык сөюче халыкларның сугышчан, бердәмлеге ныгысын!

Монголия халкының бөек рус халкы белән һәм Советлар Союзы халыклары белән туганнарча дуслыгы ныгысын!

Сезгә, сөекле Иосиф Виссарионович, Совет һәм Монголия халыкларының шатлыгы өчен озак еллар яшәү һәм сәламәтлек телибез.

**Монголия Халык Республикасының баш министры, Баш Командующий, Герой һәм Маршал—ЧОЙБАЛСАН.**

УЛАН-БАТОР.

**МОНГОЛИЯ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БАШ МИНИСТРЫ МАРШАЛ ЧОЙБАЛСАНГА**

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән Сез җибәргән дусларча котлаулар өчен Сезгә һәм Сезнең аркылы бөтен монгол халкына чын күңелдән рәхмәт белдерәм.

**И. СТАЛИН.**

Москва, Кремль 26 февраль, 1943 ел.

# *ЮЛБАШЧЫНЫҢ ПРИКАЗЫНА ҖАВАП ИТЕП*

## АЙЛЫК ПЛАННЫ 200 ПРОЦЕНТКА ҮТӘРГӘ

«Светоч» фабрикасы коллективы иптәш Сталинның приказын зур күтәренкелек белән өйрәнә һәм ул эшчеләр, хезмәткәрләр, инженер-техник работниклар арасында яңа, көчле хезмәт энтузиазмы тудыра. Тарихи приказга багышланган митингта фабрика коллективы март ае планын 200 процентка үтәргә йөкләмә алды. Бу йөкләмә һичшиксез, үтәләчәк, чөнки моңа кадәр фабрика системалы рәвештә үз планнарын бик күп арттырып үтәп килде.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә социалистик ярышка кушылганда, коллектив февраль ае планын 200 процентка үтәргә сүз биргән иде. Бу йөкләмә арттырып үтәлде. Фабрика айлык планны 24 нче февральгә 198 процент, беренче квартал планын 15 нче февральгә 130 процент итеп үтәде. Сафиуллина, Чугунова, Кузнецова һәм Миронова иптәшләрнең бригадалары элеккечә иң алда баралар: бу бригадалар көнлек заданиеләрен 200 проценттан да арттырып үтәп киләләр.

* * *

«Кызыл Шәрек» заводы коллективы, иптәш Сталинның приказын күтәренке күңел белән тыңлап үткәннән соң, беренче квартал планын 20 нче мартка үтәргә дип йөкләмә алды

* * *

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказына багышланган митинг Киез итек фабрикасының ремонт эшчеләре арасында зур дәртлелек белән үтте. Мастерлар, слесарьлар һәм механиклар югары сыйфатлы ремонтны иң кыска вакыт эчендә үтәргә булдылар.

## Кызыл Армия фондына

Азнакай районының «Шарлык» колхозы язгы чәчүгә әзерлекне уңышлы башкарып килә. Барлык культуралар буенча да чәчү орлыклары җитәрлек күләмдә салынган. Хәзер аларны җентекләп тазарту һәм тишелеп чыгышларын тикшерү бара. Машиналарга һәм сбруйларга ремонт ясау да тәмамланып килә.

Кызыл Армиябезнең фронтлардагы уңышлары белән рухланып, колхозчылар гомуми җыелыш үткәрделәр. Җыелышта Кызыл Армиябезгә булышлык итүне тагын да көчәйтү мәсьәләсе тикшерелде. Җыелыш бик җанлы үтте. Колхозчылар бу җыелыштан соң үк үз хуҗалыкларындагы запаслардан Кызыл Армия фондына 14 данә тире, 6 килограмм йон, 20 пар сескбаш һәм күп кенә бияләйләр, бер центнер ит, 3 центнер сөт һәм башка бик күп продуктлар бирделәр.

**М. КАМИЕВ.**

* * *

Данлыклы Кызыл Армиябезнең XXV еллыгы уңае белән Чепья районының «Бакча» колхозы Кызыл Армия фондына 283 центнер, «Алга» колхозы 100 центнер ашлык тапшырдылар. Бу колхозларда соңгы көннәрдә язгы чәчүгә әзерлек эшләре дә шактый көчәйде.

**Г. ГАЛИАКБЕРОВ.**

## ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕКНЕ 10 НЧЫ МАРТТА ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН

БИЕКТАУ, 27 февраль. (Телефон буенча). Кызыл Армиябезнең XXV еллыгы көнендә иптәш Сталин тарафыннан бирелгән приказны Биектау районы колхозчылары тирәнтен рухлану һәм гаять зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Приказны өйрәнү өчен колхозларда митинглар бара. «Искра», «Новомамонино», «Красная нива», «Ленинский призыв» һәм Фрунзе исемендәге колхозлардагы митинглар аеруча җанлы үттеләр һәм аларда колхозчылар актив катнаштылар. «Новомамонино» колхозы членнары батыр сугышчыларга җибәрү өчен тагын бүләкләр әзерләделәр һәм язгы чәчүгә әзерлекне 10 нчы мартка тәгәлләргә сүз бирделәр.

**С. ДИМИТРОВ.**

# ВКП(б) ның Казан шәһәр комитетының XIV нче пленумы

26 нчы февральдә ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитетының XIV нче пленумы булып үтте. Пленум хәрби хезмәткәрләр семьяларына ярдәм күрсәтү буенча совет органнарының һәм урыннардагы партия оешмаларының эшен яхшырту чаралары турындагы мәсьәләне тикшерде.

Бу мәсьәлә буенча докладны шәһәр советы башкарма комитеты председателе иптәш **Тышкевич** ясады. Ул, күп кенә предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләренең фронтовиклар семьялары турында дәүләтчә, партиячә кайгыртуларын әйтеп үтте. Ләкин әле хәрби хезмәткәрләр семьяларына җинаять төсендә бюрократларча карауны күрсәтә торган күп фактлар бар. Кайбер социаль тәэминат органнары, кайбер советларның башкарма комитетлары гадәттән тыш начар эшлиләр. Шуның нәтиҗәсендә фронтовиклар семьяларына пособиеләр түләүдә тоткарлык ясалу фактлары бар. Күп вакыт пособиеләр билгеләүне сорап бирелгән гаризалар һәм үтенечләр югалган. Шәһәр советы башкарма комитетының жалобалар буенча элекке инструкторы Присс бюрократ һм җансыз чиновник булган. Фронтовикларның һәм аларның семьяларының аңа бирелгән гаризалары айлар буена хәл ителмичә яткан. Сумаларны турыдан-туры урлау фактлары бар (аерым алганда Свердлов һәм Дзержинский районнарының социаль тәэминат бүлекләрендә).

Элемтә органнары начар эшлиләр. Почтамт гаебе буенча (директоры иптәш Богаткин) хәрби хезмәткәрләрнең семьялары җибәрелгән акчаларны һәм пенсияләрне бик соңга калып алалар.

— Бездә,—ди иптәш Тышкевич,— фронтовиклар семьяларына нормаль көнкүреш шартлары тудыру өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Моны Кызыл Армия сугышчылары, командирлары һәм политработниклары семьяларына ярдәм күрсәтү буенча үткәрелгән ун көнлекнең йомгаклары раслый. Бу вакыт эчендә уыннардагы комиссияләр меңнәрчә фронтовиклар семьяларына ярдәм күрсәттеләр, аларга 10.802 кубометр утын китерттеләр, 9.291 данә күлмәк, костюм, пальто, эчке киемнәр, 7.617 пар киез һәм күн аяк киемнәре, 4.689 метр мануфактура, 337.100 сум акчалата пособие, 2.000 поттан артык яшелчә бирделәр. 425 семьяның квартира шартлары яхшыртылды. Күп балалар бакчаларга һәм яслеләргә урнаштырылды. Ватан сугышы инвалидлары өчен аерым магазин ачылды.

Район советларының һәм шәһәр советының башкарма комитетлары, шәһәрнең партия һәм профсоюз оешмалары, барлык предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләре күрсәтелгән кимчелекләрне кичекмәстән бетерергә, фронтовиклар семьялары турында көн саен кайгыртырга, аларга игътибар бирергә һәм барлык чаралар белән булышлык итәргә тиешләр.

Доклад буенча фикер алышуларда беренче булып иптәш **Мишнев** чыкты. Ул Сталин һәм Бауман районнарының хәрби комиссарлырының эшен бик нык тәнкыйть итте. Алар хәрби хезмәткәрләр семьяларының көнкүреш шартлары белән кызыксынмыйлар, бу гаять әһәмиятле эштә үзләренең турыдан-туры булган бурычларын оныталар.

Төзү тресты партия оешмасы секретаре иптәш **Барков** сугышчылар семьяларына ярдәм күрсәтү буенча эшләнгән эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Анда, материаль яктан зур ярдәм күрсәтелүдән тыш, хәрби хезмәткәрләрнең күптән түгел производствога килгән хатыннары өчен квалификация күтәрү курслары ачылган. 400 бала өчен ашханә оештырылган.

Молотов район советы башкарма комитеты председателе иптәш **Курочкин**, районда үткәрелгән файдалы эшләр турында сөйләп үткәннән соң, күп кенә бюрократизм һәм волокита фактларын китерде. Бу фактлар аерым алганда элемтә органанрында аеруча күп.

Шәһәр социаль тәэминат бүлеге мөдире иптәш **Осипованың** чыгышы тыңлаучыларны аптырашта калдырды. Ул, һәркемне һәм бөтен нәрсәне тәнкыйть итеп бетерде, ләкин үзе җитәкчелек итә торган оешмадагы тәртипсезлекләр турында сөйләргә кирәк дип тапмады.

Шулай ук фикер алышуларда **Малкиель, Борисов, Малова, Садун, Мөлүков** һәм башка иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Соңыннан ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Шәһәр Комитеты секретаре иптәш **Колыбанов** чыкты. Иптәш Колыбанов болай диде:

— Күп кенә хәлләрдә бездә фронтовиклар семьяларына ярдәм итү эшенә формаль төстә, кампаниягә караган кебек карыйлар, үзләренең канәгатьләнерлек эшләмәүләрен кайбер саннар белән каплап калдырырга маташалар. Ләкин хәзергә әле ярдәм аз күрсәтелгән. Хәтта хәрби хезмәткәрләр семьяларының кайберләре әле тикшерелмәгән дә. Безнең оешмаларда, учерждениеләрдә, предприятиеләрдә әле бюрократизм һәм волокита бик күп. Мәсәлән, Трампаркта (социаль-көнкүреш мәсьләләре буенча директор урынбасары иптәш Петров) 547 фронтовик семьясы бар, ләкин шулардан бары 35 семья гына тикшерелгән, ә ярдәм алганнары 21 семья гына. Ләкин ул да нинди ярдәм? 24 кубометр утын һәм 900 сум акча бирелгән. Моны ярдәм дип атап булмый. Шундый ук мисалларны 2 нче номерлы икмәк заводыннан да китерергә мөмкин (директоры иптәш Дмитриев). Анда 60 хәрби хезмәткәр семьясының берсе дә тикшерелмәгән. Беркемгә дә ярдәм күрсәтелмәгән.

Иптәш Колыбанов хәзер ук үткәрергә кирәк булган чараларны күрсәтеп үтте.

— Фронтовиклар семьялары турында кампаниячә кайгыртмыйча, көн саен кайгыртып торырга кирәк. Шәһәр социаль тәэминат бүлеге, район социаль тәэминат бүлекләре органнарын, башкарма комитетларның хәрби хезмәткәрләр семьяларына ярдәм күрсәтү бүлекләрен сыналган һәм эшли алырлык кешеләр белән ныгытырга кирәк. Хәрби хезмәткәрләр семьяларына ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча һәр төрле хисапсыз күп киңәшмәләрне һәм утырышларны туктатып, көндәлек, практик эшкә күчәргә һәм бу ярдәмне күрсәтә башларга кирәк.

— Мин уйлыйм, безнең партия оешмасы булган кимчелекләрне тизлек белән төзәтә алыр. Хәрби хезмәткәрләр семьялары турында кайгырту—Кызыл Армия турында безнең бөтен кайгыртуыбызның яртысы икәнлекне һәркем аңларга тиеш.

ВКП(б) Шәһәр Комитеты пленумы үзенең карарында предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, партия һәм профсоюз оешмаларының җитәкчеләрен хәрби хезмәткәрләр семьяларының ихтыяҗларына бюрократларча җансыз карашны бик тизлек белән бетерергә, аларны ягулык белән тәэмин итү, квартираларына ремонт ясау, аяк һәм өс-баш киемнәре белән тәэмин итү, хезмәткә урнаштыру, балаларны бакчаларга һәм яслеләргә урнаштыру турында иң күп күләмдә кайгыртырга мәҗбүр итә.

Шәһәр Советы Башкарма Комитетына социаль тәэминат органнарының эшендә тәртип урнаштырырга тәкъдим ителде. 10 нчы марттан соңга калмыйча хәрби хезмәткәрләр семьяларына коллектив һәм индивидуаль түтәл бакчалары өчен җир участоклары бүлеләргә тиеш. Предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләре чәчүлек материал һәм инвентарь табуда фронтовиклар семьяларына булышлык күрсәтергә тиешләр. Военторг начальнигы иптәш Голобутога һәм Горпищеторг директоры иптәш Сәгъдетдиновка фронтовиклар семьялары файдалана торган ашханәләрнең эшләрен яхшыртырга тәкъдим ителде. Прокуратурага, хәрби хезмәткәрләр семьяларына пособиеләрне вакытында бирү һәм тиешле льготаларны бирү турындагы законнарның үтәлүен һәр вакыт күзәтеп торырга тапшырылды.

ВКП(б) Шәһәр Комитеты пленумы партия, комсомол, профсоюз, совет һәм хуҗалык оешмаларының җитәкчеләреннән, хәрби хезмәткәрләр семьяларын материаль-көнкүреш яктан тәэмин итү эше белән үзләре шөгыльләнүне таләп итә. Алар һәрбер хәрби хезмәткәрнең семьясы турында кайгыртуның хәрби-политик яктан гаять зур әһәмияте барлыгын һәм алар турында кайгырту Кызыл Армия турында безнең кайгыртуыбызның яртысы икәнлекне исләрендә тотарга тиешләр.

# Совет Информбюросыннан

## 27 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

27 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак дошманга каршы сугышта совет танкистлары немецларның 6 танкысын юк иттеләр һәм дошманның бер батальон мотопехотасын тар-мар иттеләр. Н-че часть сугышчылары, алга таба барып, танкка каршы ата торган 3 орудие, 11 станоклы пулемет, бер радиостанция һәм әйберләр склады кулга төшерделәр.

* * *

Краматорскаядан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошман танкларына һәм мотопехотасына каршы сугышлар алып бардылар. Бер участокта немецлар, халык яши торган бер зур пунктка үтәргә маташып, бер-бер артлы берничә контратака ясадылар. Безнең сугышчылар гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм 300 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Икенче бер участокта безнең артиллеристлар утлар белән немецларның 14 танкысы юк ителде. Шулай ук танклар артыннан килүче дошман мотопехотасы да шактый югалтуларга дучар ителде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары каты сугышта, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр һәм аз гына сугышканнан соң аны алдылар. 3 орудие, 15 пулемет, 100 дән артык винтовка, күп снарядлар, миналар һәм патроннар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең танклар часте немецларның 4 танкысын, танкка каршы ата торган 5 орудиесен, 11 автомашинасын юк итте һәм бер ротага якын дошман пехотасын кырды.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че часть, алга барып, халык яши торган берничә пунктны алды. 19 кыр һәм 2 зенит орудиесе, 82 пулемет, 390 винтовка, 4 трактор, 136 ат, 5.000 ящик патрон һәм бер азык склады кулга төшерелде.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немец оккупантларга каршы сугышларда 95 гитлерчыны кырып ташлаган. Партизаннар бер автомат пушка, бу пушкага күп кенә снарядлар, 3 станоклы пулемет, 6 рота минометы, 150 мина, 50 винтовка һәм берничә мең патрон кулга төшергәннәр.

* * *

Немецларның 299 нчы пехота дивизиясе, 299 нчы артиллерия полкының 12 нче батареясының, Курскидан төньяктарак пленга алынган командиры обер-лейтенант Фридрих Хейнкамп болай диде: «Сталинград районында немецларның 6 нчы армиясе юк ителгәннән соң солдатлар һәм офицерлар бөтенләй рухсызландылар. Фронтның Курск участогында да безгә авыр ударлар ясадылар. Соңгы сугышларда 299 нчы дивизия үзенең кешеләр составының кимендә яртысын югалтты. Элегрәк без, немецлар Ростов—Харьков—Курск линиясендә торып кала алырлар дип өметләнгән идек. Бу өметләр җимерелде. Үткән елны немец офицерлары Европада икенче фронт төзелүгә ышанмаганнар иде. Хәзер инде икенче фронт төзелү куркынычы барлыгына һәркем ышана. Хәзер, көнчыгышта Германия армиясе бик авыр хәлдә торганда, көнбатыштан ясаган ударның Германияне төзәтергә мөмкин булмаслык һәлакәткә китерүе мөмкин».

* * *

Бельгия патриотлары немец оккупантларга каршы үз-үзләрен аямыйча көрәшәләр. Брюссельдә немецларның һава һөҗүме оборонасы штабы бинасына бомба ташланган. 15 гитлерчы үтерелгән. Льеж районы тимер юлчылары январь аенда 25 тән артык паровозны сафтан чыгарганнар. Остенде шәһәре якынында коралы бельгиялеләр немецларның полиция отрядына һөҗүм иткәннәр һәм 28 гитлерчыны кырып ташлаганнар.

## ХӘНҖӘР

Авыр язмышыңны хәл иткәндә,
Мин читтә түгел, илем:
Кулда мылтык, өстә соры шинель,
Билемдә хәнҗәр минем.
Чигенүгә инде чик куелды,
Җитәр... оят та кирәк;
Газиз аналарны атты немец
Таш стенага терәп.
Чигенүгә инде чик куелды,
Калды окоп урманда;
Без һөҗүмгә киттек, урманнарны
Буран шаулаткан таңда.
Безнең мина, туплар ярылганда
Көнчыгыштан иде җил;
Кара тузан очты көнбатышка,
Кулымда хәнҗәр минем.
Актарыла дөнья атакада,
Куркактан үлем көлә;
Аю чаклы немец приклад селтән
Минем өстемә килә.
Куркып чигенимме? Димәк үзем
Чакырып алам үлемне;
Димәк үзем, антларымны таптап,
Утка салам илемне.
Һөҗүм итсә генә яши кеше,
Бөтен өмет һөҗүмдә;
Хәнҗәр айкап алга омтылам мин
Сызгырып искән җилдә.
Авыр язмышыңны хәл иткәндә,
Мин читтә түгел, илем:
Йөрәген тотып немец артка ава,
Сөргән кебек булды җир.

**Ф. КӘРИМ.**

Хәрәкәттәге армия.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК РАБОТНИКЛАРЫНА ЯРДӘМГӘ

# Терлек азыкларыннан дөрес һәм экономия белән файдаланырга!

**С. КОНЬКОВ,**
Казан авыл хуҗалыгы институты доценты, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты.

* * *

Терлекләрне саклау, аларның саннарын арттыру һәм концентрат азыкларны мөмкин кадәр аз тотып, терлекләрнең продуктлылыгын күтәрү—колхозларның, совхозларның һәм барлык терлекчелек работникларының сугышчан бурычы. Тупас һәм сусыл азык запасларыннан дөрес итеп, хуҗаларча файдалану булганда бу бурычны хәл итәргә бик мөмкин. Фәннең һәм практиканың күрсәтүенчә, тупас һәм сусыл азыклар әгәр дә яхшылап эшкәртелмәсәләр, аларны терлекләр яратып ашамыйлар һәм ул азыклардагы туклыклы әйберләр тулысынча файдаланылмый кала.

Академик Е. Ф. Лискун тарафыннан үткәрелгән тәҗрибәләргә караганда, саламны тик турап ашату гына да аның азык булу ягыннан тоткан урынын 10 процентка күтәрә. Чөнки ваклап туралган саламны чәйнәү өчен терлекләр азрак көч куялар. Салам 3—5 сантиметр озынлыгында туралырга тиеш.

Туралган саламның терлек азыгы булу ягыннан файдасын, аны алдан кайнар суда пешекләү юлы белән, бик нык күтәрергә мөмкин. Пешекләгәннән соң саламның тәме яхшыра, аны терлек яратып ашый һәм аны чәйнәү өчен азрак көч куя. Шулай ук бу чара саламдагы күгәрекне һәм тутыкны (гөмбә авыруларын) берникадәр йогышсызландыра.

Салам эшкәртү өчен суны гадәттә кирпеч аркылы җылытуга көйләнгән казаннарда җылыталар. Шулай ук моның өчен махсус җылыткычта әзерләргә мөмкин. Аның төзелеше бик гади. Ул берьярым метр озынлыгындагы тимер трубадан гыйбарәт. Трубаның түбәнге ягының диаметры 30—32 сантиметр, өске ягы 16—18 сантиметр. Аның аскы ягында төбе бар. Шул төпкә (трубаның эчке ягына) ягулык өчен тимер рәшәткә куелган. Бу труба янына аның төбеннән 10 сантиметр түбәнрәк итеп кечкенәрәк икенче тимер труба беркетелә. Бу икенче труба һава тарту өчен хезмәт итә. Шул су җылыткычны су салынган агач чапчакка куялар һәм су белән ул өскә күтәрелеп чыкмасын өчен беркетәләр. Ягулыкны зур трубага өстән салалар.

Саламны үз-үзеннән җылыту юлы белән әзерләү дә шулай ук бик яхшы нәтиҗә бирә. Бу эш сарайда яки терлек абзарының азык әзерләү бүлмәсендә башкарыла. Моның өчен шул бүлмәдә тирәнлеге 1,5 метр, озынлыгы 2 метр булган чокыр казыйлар. Чокырның озынлыгын һәркөн кирәк була торган азыкның күләменә карап төрлечә эшләргә мөмкин. Бер кубометр чокырга 140—150 килограмм әзер азык урнашуын искә алырга кирәк. Чокырның төбенә такта түшиләр һәм шулай ук яннарын да такта белән тышлыйлар һәм аны тоташ стеналар белән 4 секциягә бүләләр. Беренче көнне бу дүрт секциянең берсенә югарыда әйтелгәнчә туралган саламны салалар һәм салам үлчәвенә карата бер ярым яки ике өлеш җылы су белән чылаталар һәм нык итеп таптыйлар, өстән һәрбер квадрат метр мәйданга 300—400 килограмм исәбеннән йөк белән бастырып куялар. Салынганнан соң дүрт көн үткәч (4 нче көндә) беренче секциядәге саламны терлеккә ашаталар һәм шул вакытта ук бу секциягә югарыда әйтелгәнчә яңадан салам тыгалар. Икенче көнне икенче секциядәге саламны, өченче көнне өченче секциядәге саламны ашаталар.

Үз-үзеннән җылыту белән әзерләнгән саламның тәме дә пешекләнгән саламныкы кебек үк яхшы була һәм ул терлек тарафыннан тулысынча ашалып бара, салам һич тә әрәм булмый.

Печәнне рациональ рәвештә файдалануны оештырып, күп кенә концентратны рационнан бөтенләй чыгарырга мөмкин. Кузаклы культуралар печәнендә терлек өчен кирәкле туклыклы әйберләрнең бөтенесе дә җитәрлек күләмдә бар. Мәсәлән, 100 килограмм клевер печәнендә организм тарафыннан үзләштерелә торган 5,5 килограмм аксым бар. Шул кадәр сандагы бу печән үзенең туклыклылыгы белән 48—52 азык бермәлегенә яки 50 килограмм солыга тигезләнә. Люцерна печәне клевер печәненә караганда туклыклырак.

Дуңгызларның туклыклы әйберләргә булган ихтыяҗын люцерна саламы биреп ничек канәгатьләндерергә мөмкин соң? 160 килограмм авырлыгындагы буаз дуңгыз өчен тәүлегенә, составында 260 граммнан артыграк аксым булган 3 килограмм азык бермәлеге кирәк. Бу азык бермәлеген дуңгызга 6 килограмм люцерна печәне бирү белән тәэмин итәргә мөмкин. Шул кадәр печәннең туклыклыгы 3 азык бермәлегенә тигез һәм бу азыкта 600 грамм аксым бар. Бу—норма буенча тиешле аксымнан 2 тапкыр артык дигән сүз.

Ләкин люцерна печәненең дуңгызларга ашатып шундый нәтиҗә бирүенә аны онга әйләндереп бирелсә генә ирешергә мөмкин. Моның өчен иртә өлегереш вакытында һәм яхшы һавалы көнне җыеп алынган печәнне файдаланырга кирәк. Мондый печәндә терлек ашамый торган үләннәр, бигрәк тә әрем кебек үләннәр булмаска тиеш. Онга әйләндергәнчегә кадәр печәнне салам кискеч аркылы үткәрәләр һәм дымлылыгы 12—13 процент калганчыга кадәр киптерәләр. Туралган һәм киптерелгән печәнне кичекмәстән он итеп тарттырырга кирәк. Чөнки печән үзенә һавадагы дымны бик тиз җыя һәм нәтиҗәдә аны яңадан киптерергә кирәк була.

Печән онын беренче чиратта дуңгызга ашатырга кирәк. Моның өчен онны җылы суда чылаталар һәм аны куе ботка хәлендә бирәләр. Печән онындагы витаминнар югалмасын өчен пешерергә яки кайнар су белән кирәгеннән артык парларга ярамый. Печән онын пешкән бәрәңге белән катнаштырып бирергә туры килгәндә, бәрәңгене элек аерым пешерергә һәм аны печән оны белән тик терлеккә бирү алдыннан гына катнаштырырга кирәк.

**Печән утырмасы турында.** Бу азык терлекләрдә ашказаны-эчәк авыруларына каршы көрәштә иң яхшы средство булып тора.

Бу азыкны чәчәк атуының баштагы чорында һәм коры көнне җыеп алынган иң яхшы сыйфатлы печәннән әзерлиләр. Моның өчен алынган печәндә зарарлы һәм агулы үләннәр бөтенләй булмаска тиеш. Иң элек бу печәнне 3 сантиметр озынлыгында турыйлар, аннан соң аны чиста бакка яки бидонга тутыралар һәм кайнаган, җиңелчә суына башлаган су (1 килограмм печәнгә 6—7 литр исәбеннән) салалар. Шуннан соң бидонны казан эченә куялар һәм акрынлап цельсий белән 70—80 градуска кадәр җылыталар.

Судагы әнә шул температура 5 минут дәвамында үзгәрми торырга тиеш. Шулай әзерләнгән утырманы бер тәүлек буена җылы урында тоталар. Шуннан соң аны югарыда күрсәтелгән температурада яңадан җылыталар һәм шул температурада 5—10 минут тоталар. Аннан соң утырманы 36—38 градуска кадәр суыталар һәм бозауларга сөт белән яки өсте алынган сөт белән катнаштырып бирәләр.

Печән утырмасын бозауларга алар 3 атналык булгач бирә башлыйлар, башта 0,25 литр бирәләр, ә инде бозаулар бер айлык булганда норманы акрынлап тәүлегенә 0,75—1,0 литрга кадәр җиткерәләр. Бозаулар ике айлык булгач бу азыкны 3—3,5 литрга кадәр бирергә мөмкин. Печән утырмасы бозау рационын туклыклы әйберләргә генә түгел, витаминнарга да баета.

**Силос турында.** Силос башняларын һәм траншейларны ачкан вакытта силосны пычратмаска кирәк. Траншейны бер үк вакытта бөтенләй ачмаска, ә кирәк кадәр генә ачарга кирәк. Чокыр һәм башнялардагы силосның өсте бөтенләй ачыла һәм һәркөнне кирәк кадәр силос алып барыла. Силосны барлык терлекләргә дә ашатырга мөмкин. Ләкин атларга силосны яхшы сыйфатлы булса гына бирергә мөмкин.

Силосны дуңгызларга, әлбәттә, ваклап бирергә кирәк. Шулай ук силосны дуңгызларга пешереп тә бирергә була.

Терлеккә туңган силос бирергә ярамый. Элек аны эретергә һәм кичекмәстән ашатырга кирәк. Сыерларга силосны көн саен 20 килограмм, атларга 8 килограммга кадәр, дуңгызларга 4,5, сарыкларга 3—4 килограмм бирергә мөмкин.

Терлекләргә азыкны дөрес бирү нәтиҗәсендә терлекчелекне үстерү буенча бик яхшы уңышларга ирешергә була.

# Урман—утын әзерләү планын срогыннан алда үтик!

*Кукмара районы колхозчыларының һәм колхозчы хатын-кызларының мөрәҗәгате*

Кызыл Армиянең батыр гаскәрләре, һөҗүмне уңышлы рәвештә җәелдереп, яңадан-яңа шәһәрләрне һәм авылларны немец басып алучылардан азат итәләр. Фронтлардан килгән күңелле хәбәрләр хезмәт ияләренең йөрәкләрендә шатлык тудыралар, һәрбер эшчене һәм колхозчыны алдагы зур җиңү хакына тагын да тырышыбрак эшләүгә рухландыралар.

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның тарихи приказы бөтен илдә киң күләмдә өйрәнелә. Юлбашчының чакыруына җавап итеп, һәркайда да бөек Беренче Май бәйрәмен лаеклы рәвештә каршылау өчен социалистик ярыш җәелеп бара.

Фронтның иң әһәмиятле заказларын үтәүче промышленность өчен, гаять күп сугыш йөкләре ташучы транспорт өчен, Кызыл Армия тарафыннан азат ителгән өлкәләрнең һәм районнарның хуҗалыгын аякка бастыру өчен күп агач һәм ягулык кирәк.

Без, Кукмара районы колхозчылары, моны бик яхшы аңлыйбыз һәм, агач һәм утын әзерләүдә эшләп, темпларны көннән-көн көчәйтергә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга омтылабыз. Агач әзерләү буенча безнең район өчен билгеләнгән көзге-кышкы сезон планы 20 нче февральгә 65,6 процентка һәм агач ташу буенча 81 процентка үтәлде.

«Горд Коммунар» колхозыннан иптәш Никифоров җитәкчелегендәге урман кисүчеләр бригадасы югары эшләп чыгарыш үрнәкләре күрсәтте. Ул сезон заданиесен 15 нче февральдә тулысынча тәгәлләде. «Труженик» колхозыннан иптәш Бочкарев җитәкчелегендәге урман ташучылар бригадасы планны срогыннан алда үтәде. «Пчеловод», «Ясная Поляна», «Октябрь ялкыны» һәм башка артельләрнең дә колхозчылары үзләренең ватан каршындагы бурычларын намус белән үтиләр.

Безнең фикерләребез һәм омтылышларыбыз тагын да яхшырак эшләүгә, бөтен көчебезне фронтка ярдәмгә бирүгә юнәлдерелгән. Без, агач әзерләү һәм ташу буенча сезон заданиесен 15 нче мартка үтәп бетерергә дип бер тавыштан карар бирдек. Моның өчен без социалистик ярышны тагын да җәелдерербез, урман кисү инструментларын тагын да күбрәк кулланырбыз, тарту көченнән нәтиҗәле итеп файдаланырбыз.

Без, республикабыздагы барлык колхозчыларга мөрәҗәгать итеп, алдагы март аен Дәүләт Оборона Комитеты билгеләгән сезон планын срогыннан алда тәгәлләү ае дип игълан итәргә чакырабыз.

Колхозчы иптәшләр! Урман-утын әзерләү планын уңышлы тәгәлләү өчен, сугыш вакытындагы икенче язга үрнәк булырлык итеп әзерләнү өчен социалистик ярышка кушылыгыз. Дошманны тизрәк тар-мар итү эшенә бөтен көчегезне, бөтен энергиягезне бирегез!

Кукмара районы колхозчыларының тапшыруы буенча: ВКП(б) райкомы секретаре **Денисов**, район советы башкарма комитеты председателе **Җәгъфәров**, «Ясная поляна» колхозы председателе **Пичугин**, «Труженик» колхозы бригадиры **Бочкарев**, район советы башкарма комитеты уполномоченные **Рыжков**, урман әзерләү пункты мастеры **Николаев**, урман кисүче, «Яңа юл» колхозыннан **Сәмигуллин**, Киров исемендәге колхоз члены, агач ташучы **Сафина**, «Динамо» колхозы члены, агач ташучы **Вәлиева** һәм башкалар—барлыгы 40 кеше кул куйган.

# СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

## 27 нче февральдәге кичке белдерү

27 нче февральдә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның бер миноносецын батырдылар.

* * *

26 нчы февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар. 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак немецлар моннан элек безнең подразделениеләр алган уңайлы позицияләрне кире кайтарып алырга маташтылар. Н-че часть сугышчылары дошманның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Икенче бер участокта безнең частьлар 14 пулемет, 250 винтовка, эре калибрлы 3 пулемет һәм 8 кул пулеметы кулга төшерделәр.

* * *

Ворошиловградтан көньяк - көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары бик каты сугышта немецларның көчәйтелгән пехота батальонын тар-мар иттеләр. Дошман, сугыш кырында бик күп үле гәүдәләр һәм яндырылган 2 танк калдырып, чигенде. Кулга төшерелгән трофейлар арасында 4 орудие, 7 миномет, күп винтовкалар һәм сугыш припаслары бар.

* * *

Краматорскаядан көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошман танкларына һәм мотопехотасына каршы бик каты сугышлар алып бардылар. Немецлар, бик күп танклар туплап, халык яши торган бер зур пунктка бәреп керергә маташып карадылар. Безнең артиллериябез һәм бронебойщикларыбыз уты белән, шулай ук танкка каршы гранаталар белән немецларның 28 танкысы юк ителде. 400 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. Дошманның калган танклары ашыгыч рәвештә элекке позицияләренә чигенделәр.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган күп кенә зур пунктларны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта гына да 150 дән артык гитлерчы кырып ташланды, дошманның 6 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Совет сугышчылары 2 самоход орудие, танкка каршы ата торган 6 орудие, 2 сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын кулга төшерделәр.

Безнең авиациябез дошманның Запорожьедәге аэродромында немецларның 18 бомбардировщигын юк итте һәм яндырды.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че берләшмә частьлары алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсендә аеруча каты сугышлар булды. Аның урамнарында гитлерчыларның 200 дән артык үле гәүдәләре табылды. Икенче бер участокта немецлар контратакага, танклар һәм бронемашиналар ярдәме белән, бер батальон пехота җибәрделәр. Совет бронебойщиклары дошманның 3 танкысын һәм 2 бронемашинасын зарарладылар һәм яндырдылар. Ярдәмчесез калган немец пехотасы зур югалтуларга дучар ителде һәм тәртипсез рәвештә чигенде.

* * *

Сумы өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары февральның 15 көне эчендә халык яши торган берничә пунктта немец гарнизоннарын юк иткәннәр. 7 пулемет, 350 винтовка, сугыш йөкләре төялгән 9 автомашина һәм 150 повозка, 200 ат, 30 ияр һәм 40 килограмм шартлый торган әйберләр кулга төшерелгән. Украинаның икенче бер отрядының партизаннары венгерлар полкы штабын туздырганнар. 10 штаб офицеры үтерелгән. 3 радиостанция һәм штаб документлары кулга төшерелгән.

* * *

Немецларның 3 нче танк дивизиясенең 75 нче артиллерия полкыннан плен алынган обер-ефрейтор Карл Кирниох болай диде: «Руслар һөҗүм башлангач 75 нче артиллерия полкы оборона линиясенә урнашырга һәм аны ничек кенә итеп булса да тотып калырга приказ алды. Ләкин руслар безгә моңа ирек бирмәделәр. Офицерлар, бу чиктә полк кыш буена торачак һәм яз көне Кавказга каршы яңа һөҗүм башланачак, диделәр. Тормыш бу исәпләрнең барысын да аударып ташлады. Русларның басымы шул кадәр көчле булды, хәтта безгә алдан ясап куелган ныгытмалар да ярдәм итмәде. Немецлар армиясе, Кавказны һәм Кубаньны калдырып, артка таба тәгәрәде. Солдатлар фронт линиясен тигезләү турындагы һәр төрле сөйләнүләрне бик тали генә аңлыйлар: немец гаскәрләре чигенәләр, чөнки руслар һөҗүм итәләр. Без аларның басымына каршы тора алмыйбыз. Гомумән Кавказга һәм Бакуга карата эшләнгән бу эшләр барысы да авантюра булып чыктылар. Хәзер инде боларның барысы өчен дә түләргә туры килә».

* * *

Курск өлкәсенең Битюг авылында немец-фашист кабәхәтләр күп кешеләрне үтергәнче газаплаганнар. Гитлерчы палачлар, агалы-энеле Захар һәм Василий Казначеевларны аларның ата-аналары алдында атып үтергәннәр. Немец юлбасарларның бер нәрсәдә дә гаепләре булмаган мәктәп балаларын җәзалауларына каршы укытучы Мария Степановна Дородных протест белдергән. Фашист бандитлар бу совет патриоткасын тотып алып, асып үтергәннәр. Чигенер алдыннан гитлерчылар бер төркем халыкны подвалларга куып керткәннәр һәм подвалларга бензин сибеп ут төрткәннәр. 40 тан артык кеше, күпчелеге хатын-кызлар һәм балалар, утта янып үлгән.

# ҺИНДСТАНДАГЫ ХӘЛ ТУРЫНДА

ЛОНДОН, 26 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Бомбейда Һиндстанның политик лидерларының конференциясе булган. Конференциядә либераллар лидеры Багадур Сапру Гандины бик тизлек белән азат итүне таләп итеп чыккан.

Конференциядә сайланган комитет Черчилльгә телеграмма җибәргән. Бу телеграммада Һиндстанның җәмәгать оешмаларының төрле группаларын, төрле диннәрне һәм төрле интересларны яклаучы 300 вәкилләнең Гандины бик тизлек белән һәм һичбер шартсыз азат итүне таләп итә торган резолюция кабул иткәнлекләре әйтелә, чөнки ачыгу аркасында Гандиның сәламәтлек хәлендә кризис башланган. Аннары шул ук телеграммада Гандиның Һиндстан хөкүмәте тарафыннан игълан ителгән хаты аны һәм Һиндстан милли конгрессын Һиндстанда бара торган чуалышларда гаепләүне җитәрлек кадәр ачык итеп кире кагуы әйтелә. Хәтта әйтелүенчә, әгәр дә Ганди коткарылса, тынычлык һәм ирекле килешү юлы ачылачак, ә инде Гандиның үлүе Һиндстан җәмәгатьчелегендә ачу тудырырга мөмкин. Илдә бара торган чуалышларның шактый өлеше хөкүмәтнең үткән елның җәендәге хәрәкәтләре аркасында килеп чыккан.

Аннан соң телеграммада, бу резолюциянең Һиндстан вице-королена күрсәтелгәнлеге һәм аның үзенең элекке карарларын үзгәртүдән баш тартуы әйтелә. Шул уңай белән комитет Гандины коткару өчен җаваплылыкны бары тик Һиндстан хөкүмәтенә генә йөкли һәм бу телеграмманы Англия парламентына җиткерүне сорый. Телеграммага Багадур Сапру, Мадрас провинциясенең элекке баш министры Раджогопалачария, мөселманнарның «Азат» оешмасы председателе Алла Бакш, Һинду оешмасы секретаре Махасабха Мунде, Һиндстан коммунистлар партиясе үзәк комитеты вәкиле Ранадив, профсоюзлар конгрессының генеральный секретаре Джоши һәм һиндлеләрнең, мөселманнарның, хрестианнарның, сәүдә промышленность һәм авыл хуҗалыгы даирәләренең башка вәкилләре кул куйган.

Черчилль Багадур Сапруга җавап телеграммасы җибәргән. Бу телеграммада Гандины һәм конгрессның башка лидерларын кулга алу турындагы карарны кабул итүгә булган сәбәпләрнең бетмәгәнлеге әйтелә. Аннары телеграммада болай диелә: «Һиндстан һәм Бөек Британия хөкүмәтләренең иң беренче бурычы,— Һиндстанны дошманның басып керүеннән саклау һәм берләшкән милләтләрнең гомуми эшендә Һиндстанга мәгълүм роль уйнарга мөмкинлек бирергә шартлар тудыру булырга тиеш. Һиндстан хөкүмәте Гандиның ачлык игълан итү юлы белән, үзен һичбер шартсыз коткаруга ирешергә тырышуына карап, Һиндстан хөкүмәтенә үзенең Һиндстанга һәм берләшкән милләтләргә карата булган йөкләмәләрен үтәүдән баш тартмас, дип белдергән иде. Англия хөкүмәте Һиндстан хөкүмәтенең бу карарын яклый».

## СӨХӘЙЛИ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ДЕКЛАРАЦИЯСЕ

ТАҺРАН, 26 февраль. (ТАСС). Иранның министрлар советы председателе Сөхәйли, мәҗлестә речь белән чыгып, Иранның яңа хөкүмәте политикасының төп линияләрен аңлатып биргән. Сөхәйлинең әйтүенчә, Иран хөкүмәтенең программасы тышкы политика өлкәсендә дус һәм күрше державалар белән мөнәсәбәтләрне ныгытуны һәм бигрәк тә союздаш дәүләтләр һәм Америка Кушма Штатлары белән якын хезмәттәшлекне күздә тота. Эчке политика өлкәсендә бу программа халыкны азык белән тәэмин итүне, кыйммәтчелекне бетерүне, авыл хуҗалыгына, сәламәтлек саклауга һәм мәгарифкә кагыла торган кирәкле чаралар үткәрүне күздә тота.

Сөхәйлинең речennән соң мәҗлес күпчелек тавыш белән хөкүмәткә ышаныч резолюциясе кабул иткән. Мәҗлеснең 132 депутатыннан 99 кеше тавыш бирүдә катнашкан, шулардан 89 кеше хөкүмәткә ышаныч резолюциясенә тавыш биргән

## АНГЛИЯ БОМБАРДИРОВЩИКЛАРЫНЫҢ НЮРНБЕРГКА ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 26 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 26 нчы февральгә каршы төндә Нюрнберг шәһәренең бик каты бомбага тотылганлыгы Лондонда рәсми рәвештә игълан ителгән. Шуның өстенә Көнбатыш Германиядәге төрле объектларга һөҗүм ясалган. 9 самолет үз базаларына кайтмаган.

## АМЕРИКА БОМБАРДИРОВЩИКЛАРЫНЫҢ НЕАПОЛЬГӘ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 26 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, үткән төнне Америка бомбардировщикларының Неапольгә һөҗүм иткәнлекләре Каһирәдә рәсми рәвештә игълан ителгән.

## Туниста сугыш хәрәкәтләре

ЛОНДОН, 26 февраль. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы коралды көчләре штабының белдерүендә Кассерин тау аралыгының хәзер союзниклар гаскәрләре кулында икәнлеге әйтелә. Англия һәм Америка пехотасы, танклар ярдәме белән, дошманның арттагы сафларына уңышлы атака ясаган һәм тау аралыгында калган барлык дошман частьларын чигенергә мәҗбүр иткән. Шулай ук союзниклар бу тау аралыгыннан төньяк-көнчыгыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак булган биеклекләрне дә үз кулларында тоталар.

Сбиба районында союзниклар гаскәрләре чигенүче дошманны куып барганнар һәм 10-15 миль алга киткәннәр.

## БЕЛДЕРҮ

Шушы елның 2 нче мартында, 19 сәгатьтә, ВКП(б) ның Өлкә һәм Шәһәр комитетларының партия мәгарифе йортында шәһәр докладчылары өчен инструктив доклад үткәрелә. Тема: Халыкара хатын-кызлар көне — 8 нче март. Докладчы иптәш Мелещенко.

Җаваплы редактор И. УЗБЕКОВ.

## Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген иртә белән — *„Печән өстендәге эт"*, кич — *„Хуҗа Насретдин"*. 4 нче мартта — *„Мәйсәрәнең хәйләсе"*.

Зур драма театры. Бүген иртә белән — *„Нашествие"*, кич — *„Фронт"*.

Яшь тамашачылар театры. Бүген 12 сәгать 30 минутта һәм 4 сәгатьтә — *„Иванушка һәм гүзәл Василиса турында әкият,"* кич — 8 сәгатьтә *„Москвичка"*.

Татарстан дәүләт филармониясе. Татар дәүләт академия театры бинасында зур *концерт*. Концерттан соң төнге 2 сәгатькә кадәр танецлар. Бөтен җыелган акча танклар колоннасы төзү фондына биреләчәк. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро" — *„Җиңелмәслекләр"*.

„Унион" — *„Таҗикстан улы"*.

„Пионер" көндез һәм кич *„Райком секретаре"*.

„Чаткы" — *„Антоша Рыбкин"*.

## ПОЛЬША ИЛЧЕСЕ РОМЕР ӘФӘНДЕНЕ СССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ И. В. СТАЛИННЫҢ КАБУЛ ИТҮЕ

26 нчы февральдә СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе иптәш И. В. Сталин Польша илчесе Ромер әфәндене кабул итте.

Беседада Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов катнашты.

КЕЧКЕНӘ ФЕЛЬЕТОН

## *Тормышлары кыскара...*

Ганс белән Фриц хәзер могаен шулай сөйләшәләрдер:

— Калма артка, калма, Фриц. чап кызурак!..

— Чабам, Ганс, чабам!..! Уф!..

— Линияләрне кыскартабызмы, Фриц?

— Кыскартабыз, Ганс. Менә шулай чабып чигенгән саен линияләр кыскаручан була икән ул...

Ганс белән Фриц аз гына тын ала алганда түбәндәгечә дә сөйләшеп үткәли торганнардыр:

— Былтыр кыш, Фриц, безгә әллә кием булмаганга сизелде, әллә кыш булганга киемсезлек сизелде, шайтан белсен...

— Аның каравы, бу кыш кызу. Безгә дә, Берлинга да кызу. Җәйге челләмени!..

— Ә мин, Фриц, шуны аңламыйм: Иван белән Степан, кыш диган булып, киез итек, туннар кигән булсалар да, безне куыпмы-куалар, хәтта безне узып та китеп, линияләребезне өзәләр.

— Әйтер җирең, сөйләр урының бармы, Ганс. Ничек итеп, аз гына булса да тирләмиләр эле диген...

— Дәшмә, Фриц: Иван белән Степан да безнең командованиенең боерыгын үтиләр. Безнең арттан төшеп, линияләрне кыскартышалар... Чап, чап, Фриц, калма!..

— Чабам, Ганс, чабам, хәтта җәйге фельдеперс кофтамны да салып ташладым инде... Уф!..

Борчак сибүче, маймыл Геббельс та «Сугыш линиясен кыскартабыз» өстенә тагын шулай дип тә дөньяны шартлатып яңгыратачак:

— Большевиклар Свердловск шәһәрен алдык, диләр. Ышанмагыз. Чөнки Свердловск диган шәһәр Уралда ул. Ә Уралга без җитмәкче идек... Китмәкче булдык. Ягъни сугыш линияләрен кыскартабыз...

Ә без исә шуны гына әйтәбез: кабахәт дошманның сугыш линияләре генә түгел, тормыш линияләре дә кыскара. Батыр Кызыл Армиянең тагын да берничә көчле ударларыннан соң мәлгуннарның тормыш линияләре тәмам өзгәләнеп, теткәләнеп бетәчәк. Шакшылар моны көтсеннәр. Кабер такталарына заказлар бирсеннәр, өлгерсәләр.

И. ТУКТАРОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары — АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге — АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1063 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 314